| | |
| --- | --- |
| МИНИСТЕРСТВО ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ |

11.06.2017 Казан ш. № 8-05-п/77

Татарстан Республикасында яшәүче картасы проектын, Татарстан Республикасында яшәүчеләр карталары реестрының Веб-сервисына һәм Татарстан Республикасында яшәүче картасын чыгару (кабат чыгару) өчен кирәкле мәгълүматка керү мөмкинлеген гамәлгә ашыруда катнашучы кредит оешмаларына дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 01.07.2016 № П-92 боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым караларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2010 № 880 карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибе нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

«Татарстан Республикасында яшәүче картасы проектын, Татарстан Республикасында яшәүчеләр карталары реестрының Веб-сервисына һәм Татарстан Республикасында яшәүче картасын чыгару (кабат чыгару) өчен кирәкле мәгълүматка керү мөмкинлеген гамәлгә ашыруда катнашучы кредит
оешмаларына дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасында яшәүче картасы проектын, Татарстан Республикасында яшәүчеләр карталары реестрының Веб-сервисына һәм Татарстан Республикасында яшәүче картасын чыгару (кабат чыгару) өчен кирәкле мәгълүматка керү мөмкинлеген гамәлгә ашыруда катнашучы кредит оешмаларына дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә

министрлыгының 01.07.2016 № П-92 боерыгы белән расланган административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 27 июлендәге 2010 елның № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) («РФ Законнар җыелмасы», 02.08.2010, № 31, ст. 4179, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге № 63-ФЗ Федераль закон нигезендә («РФ Законнар җыелмасы», 11.04.2011, № 15, ст. 2036, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 06.07.2005 №318 карары белән расланган нигезләмә (алга таба – Министрлык турында нигезләмә) нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып (карар тексты «Татарстан Республикасы законнар җыелмасы» журналының № 47да басылган, 2016 елның 23 декабре);

«Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2010 № 880 карары нигезендә (алга таба – №880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) нигезендә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыелмасы, 23.08.2006, № 46, ст. 2144, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Министрлар Кабинетының 13.05.2016 №857-р күрсәтмәсе нигезендә, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыелмасы, 21.06.2016, №45, ст. 1445, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Регламентның 2.4 пунктындагы «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының дүртенче абзацының үз көчен югалтуын таныргa;

5.1 пунктның алтынчы, җиденче һәм сигезенче абзацларында слова «әлеге Регламент» сүзләрен «Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары һәм әлеге Регламент» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән төгәлсезлекләрне һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләр кертүнең билгеләнгән срокларын бозуы.».

Татарстан Республикасы

Премьер-министры урынбасары–министр Р.А. Шәйхетдинов